

ISSN 0868-4545

Салават күпере

Игътибар! Бәйге дәвам итә!

Шүрәле малае Шүркә




Тукай абый өйрәтә

Бара торгач, Шүркәне очрата Шамил. «Бу синме, мактанчык малай?» – ди Шүркә. «Әйе, – ди Шамил. – Ә син шул акыллы Шүркәмени?» Шүркә әйткән: «Әйе, мин акыллы, чөнки мәктәпкә йөрим, өй эшен эшлим һәм Габдулла Тукайның бөтен шигырьләрен яттан беләм!»

Шуннан соң Шамил дәресләрне калдырмый башлаган һәм Тукай абыйның барлык шигырьләрен, әкиятләрен яттан өйрәнгән.

Ләйсән ГАЛИМУЛЛИНА, 8 яшь.
Кукмара, 2 нче мәктәп.



Айсылу ЙОСЫПОВА, 8 яшь.
Тукай, Хуҗи.



Азилә НАСРЕТДИНОВА, 10 яшь.
Мөслим, Әмәкәй.

Тылсымчы бабай

Шамил Шүркә белән бергә урман буйлап китә. Бераз баргач, Шамил еракта бер шәүлә күрә: куак артыннан матур кием кигән ак сакаллы бер бабай килеп чыга. Кулына алтын каләм белән дәфтәр, китап тоткан бу. Бабай Шамил янына килеп баса да: «Шамил улым, мәктәпкә йөрисеңме, әкиятләр укыйсыңмы?» – дип сорау бирә. Шамил йокысыннан уянган кебек була. «Шүрәле» әкиятен дә белмәвеннән бик ояла. Шул көннән башлап Шамил Шүркә каршында тылсымчы бабайга сүз бирә: «Бик яхшы билгеләргә генә укырмын, укытучыларны, әти-әнине тыңлармын!» – ди ул.

Ильяс ГАНИЕВ, 7 яшь.
Буа, Карлы.

© «Салават күпере», 2008 ел

Бер партада

Сызгыра-сызгыра барып җиткән, ди, Шамил урманга. Барып та җиткән, аны-моны уйламыйча, артын-алдын карамыйча, урман ешлыгына кереп тә киткән. Куакларны аралап, матур чәчәкләрне таптап, гел эчкәрәк кергән малай. Керүен кергән дә бит, берзаман үзенең адашканлыгын аңлаган бу. Ләкин инде соң булган, кайтыр юлын таба алмаган. Тамагы ачыккач, күзенә чалынган җиләкләрне җыеп ашаган. Кайсылары шифалы, ә ниндиләре агулы икәнлеген аера белмәгән шул ул. Чөнки мәктәптә «Әйләнә-тирә дөнья» дәресләрен бер дә кирәкле фәнгә санамаган, укытучысын да санламаган.

Менә берзаман Шамилнең башы әйләнә, эче авырта башлаган. Малай агач төбенә утырган да, түзә алмыйча, кычкырып елап җибәргән. Аның тавышына урманның барча шүрәлеләре җыелган. Хәлне аңлатып биргәч, Шамилгә ярдәм итәргә ашыкканнар, чөнки алар бер дә явыз булмаганнар. Шүркә, урман чишмәсеннән алып, малайга тереклек суы эчергән, дару үләннәре җыеп китергән.

Шамилнең хәле яхшыргач, аны урман белән таныштырган. Сирәк очрый торган чәчәкләрне, агулы үсемлекләрне аерып күрсәткән. Адашкан очракта, агач ябалдашларына һәм кырмыска оясына карап, юнәлешне билгеләргә, юл табарга өйрәткән. Чөнки Урман мәктәбендә гел «бишле»гә генә укыган икән Шүркә!

Ул Шамилне урман авызына кадәр озата чыккан. Шамил үзенең кыланмышлары өчен бик нык оялган, гафу үтенгән. Төзәлергә сүз биреп, яңа дустына рәхмәт әйтеп өенә кайтып киткән.

Белмим, урман һавасы килешкәнме, Шүркәнең сабагы үтемле булганмы – шул көннән башлап Шамил тәмам акылга утырган. Тискәре гадәтләрен ташлаган, тырышып укый башлаган.

Хәзер Шүркә дә Урман мәктәбен тәмамлап, авылдагы урта мәктәпкә укырга йөри, ди. Шамил белән бер сыйныфта, бер партада ярыша-ярыша укыйлар, имеш.

Рәзил КОРБАНОВ, 9 яшь.
Әтнә, Иске Җогып.



*Марат ЗАРИПОВ, 11 яшь.
Актаныш, Кыркаентүбә.*



*Румия ХАЛИКОВА, 12 яшь.
Кукмара, Тат.Тулба.*

Шүркәнең шигъри сүзе

Тукайны өйрәнмәгәч,
Китап-дәфтәр алмагач,
Шүркәне дә танымыйсың,
Мәктәпне яратмагач!

Тукай бабай «Шүрәле»сен
Бөтен балалар белә.
Күрәсеңме, укымагач,
Синнән сыер да көлә.

Әй Шамил, Шамил дускай!
Калма болай көлкегә.
Кирелегеңне җиң дә
Укый башла «бишле»гә.

Нурзил ГАЛИМУЛЛИН, 12 яшь.
Саба, Сәрдә.



Илүзә ВАХИТОВА.
Кама Тамагы, Яңа Сала.

Шүркә белән Шамил


Шамил, урманга керер алдыннан, өч юл чаты күргән. Өч юл уртасында олы бер таш утырган. «Уңга барсаң, әкият геройлары белән очрашырсың; сулга барсаң «Урман мәктәбе»нә эләгерсең; турыга барсаң, аң-белем алып чыгарсың», дип язылган. Шамил бераз уйланган да: «Нигә кирәк миңа белем? Мин болай да акыллы инде! Шүркәне койрыгыннан каптырыр, мөгезеннән тотар өчен, әлбәттә, уңга барасы бит», – дигән. Бара икән бу, бара... Урман куерганнан куера, нәфис буйлы каен, усак агачлары картаеп беткән кәкре имәннәр белән алышына. Ниһаять, дустыбыз Шамил әкият геройлары авылына килеп тә җиткән. «Убырлы карт» ишегенә берничә кат шакыган, чыгучы булмаган. Алга таба киткән – Су анасы, Йорт иясе, Пәри ишекләренә чирткән, әмма берсе дә өйдә юк икән. «Шүрәле абзый» йортын күргәч, әй шатланган Шамил, бөтен көче белән ишекне дөмбәсләргә тотынган. Чыгучы булмаган. Шуннан «Урман мәктәбе»нә киткән бу. Бара торгач мәктәп тә күренгән. «Әй син, Шүркә, әйдә көрәшкә чык!» – дип кычкырган малай. Тәрәзәләрдән халык күренгән. Шуннан берсе: «Нәрсә кирәк сиңа, малай?» – дигән. «Шүркә дигән бер әкәмәт кирәк иде», – дип җавап кайтарган Шамил. Шуннан ул артына борылып караган һәм Шүркәне күреп алган. «Беренчедән, мин әкәмәт түгел, ә Шүрәле малае, икенчедән, вакыт юк, әйдә, эшкә керешәбез!» – дигән Шүркә. «Нинди эшкә?» – дип аптырап калган малай. «Ничек нинди, сиңа акыл өйрәтәбез!» «Ы-ы, шулай булды ди! Кирәксә, үзем өйрәнәм! Мине,

барыбер, берсе дә өйрәтә алмаячак!» – дигән Шамил. «Әгәр сине аң-белемгә өйрәтә алсам, миңа «Рәхмәт!» дип әйтерсең, – дигән Шүркә. – Әгәр өйрәтә алмасам, мөгездән тотып алырсың!» «Килештек! Йә, ничек мине укытмакчы буласың?» – дип масаеп дәшкән Шамил. «Без синең белән ерак-ерак гасырларга китәрбез», – дигән Шүркә һәм Шамилне Вакыт машинасына утырткан. Бергәләп олы сәфәргә кузгалганнар. Архимед, Галилео Галилей заманыннан алып бүгенгә чаклы сәяхәт иткәннәр. Вакыт машинасыннан чыккач, Шамил шатлыгыннан ни әйтергә белми икән. Тарихның бер дәресенә дә кермәгәнгә күрә, вакыт буйлап сәяхәт итү Шамил өчен иң тылсымлы могҗиза булып тоелган. «Менә күрәсеңме, Шамил дус, акыллы булсаң нинди уңышларга ирешергә мөмкин? Менә алыйк Александр Македонскийны. Ул бит дошман гаскәрен көч белән түгел, зирәклеге, белем аркасында җиңгән. Исеңдә тот: «Белемсез – берне, белемле меңне егар». «И Шүркә, белемсезлек батсаклыгыннан тартып чыгарганың өчен рәхмәт сиңа. Бүген үк, юк, иртәгә үк, һичшиксез, мәктәпкә барам!» – дигән Шамил.



Юлия Закирова (уңда) дусты Альбина белән.

Юлия ЗАКИРОВА, 11 яшь.
Чаллы.



Альбина САЗАЕВА, 10 яшь.
Мамадыш, Юкәче.



Алия МАННАПОВА, 8 яшь.
Актаныш, 2 нче урта мәктәп.



Такмак язучы каләм

Фәриткә әтисе бик матур каләм бүләк итте.

– Улым, бу гади каләм түгел – тылсымлы каләм! – диде ул.

Тылсымлы каләм?! Кызы-ы-ык. Нинди тылсымы, нинди сере бар икән моның?

Фәрит өстәл янына килеп утырды да яшел алма төсендәге дәфтәрен ачып куйды. Ачып куюы булды... менә хикмәт!.. менә әкәмәт!.. Әлеге каләм ап-ак биткә хәрефләр, сүзләр тезә башлады. Каләмнең тиз хәрәкәтләнүенә Фәритнең күзләре ияреп өлгерәлми хәтта.

Каләм яза да яза. Ул ни яза икән, дип Фәрит кәгазьдәге язуларга күзен төшерде. Бәй, такмаклар ич бу! Кызыклы такмаклар:



Иртән торып тышка чыксам
Биеп йөри алаша.
Ике чеби утын кисә –
Менә сиңа тамаша!

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Әнә килә автомобиль,
Йөртүчесе – ак тавык.
Былтыр алган «бишле» өчен
Йөрмә бүген мактанып!







Туктаталмыйм, дигәннән... Каләм яза да яза, яза да яза... Фәрит аны язуыннан ничек туктатырга белми изаланды. Ярый әле шулчак әтисе пәйда булды.

– Бүгенгә җитәр, улым. Шулай бит?! – диде ул, елмаеп. – Ял итсен. Каләмгә дә ял кирәк!





Бал кортлары

Бал кортлары «без-без» килеп,
Бик күңелле яшиләр.
Тик торуны белми алар,
Көне буе эшлиләр.

Иртән кояш чыгу белән
Очалар еракларга,
Чәчәктән чәчәккә кунып,
Тәмле нектар җыярга.

«Балның мең шифасы бар», – дип,
Мактап туймый бабай да.
Бал кортлары кешеләргә
Китерә бик зур файда.

Римма ШӘЕХОВА, 15 яшь.
Азнакай.



Рәзилә ӘХМӘДУЛЛИНА, 7 яшь.
Әтнә, Күәм.



Ләйсән МУЛЛАГАЛИЕВА, 10 яшь.
Башкортостан, Әлшәй, Түбән Әүрүз.

Гүзәл кала

Нократ буе чишмәләре...
Кемнәр суын эчмидер.
Беләм, суларың шифалы,
Халкың шуңа көчледер.
Һәркем эшли, ару белми,
Шуңа матур син, калам.
Еракларда җирсеп, сагынып,
Кайта сиңа һәр балаң.
Мамадышым – гүзәл калам,
Синнән мин көч-дәрт алам.
Матур булып, затлы булып,
Яшә син, данлы калам!

Назилә ХӘСӘНОВА, 10 яшь.
Мамадыш, 2 нче урта мәктәп.



Эльза ВАСИЛЬЕВА, 7 яшь.
Кукмара, Кызыл Таулар.

Чистай районы Дүрт-Өйле мәктәбенең 2 сыйныф укучылары рәсемнәре



Инсаф НУРЕТДИНОВ.



Рәсим МУСАБИРОВ.



Фәния ИБРАҺИМОВА.



Илүзә САБИРҖАНОВА.



Фирүзә МИНГАЛИМОВА.



Нурислам ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.

Кышкы кошлар

Урамда бүген салкын –
Кошлар качкан сарайга.
Ярыктан карый алар
Өйдә йөргән бабайга.

«Килсен иде җылы яз,
Эресен иде карлар...
Тамагыбыз туяр иде» –
Диеп уйлыйдыр алар.

Бабай кошларны җәлли –
Бодай сибә аларга:
«Түзегез, – ди, – кошкайлар,
Күп калмады язларга...»

Ренат АЛИЕВ, 10 яшь.
Әлки, Базарлы Матак.




Алинә, 7 яшь

– Абыем да бар минем,
Бабаем да бар минем.
Абыйсыз һәм бабайсыз мин
Бер кая да бармыймын!

Актаныш, Такталачык.

Мин бит бу!




Булат, 4 яшь

– Идән тулы машина,
Өстәл тулы машина.
Барып кайтасы җирем бар,
Утырыйм, дим, кайсына?

Казан.


Нәфисә,
2 яшь 5 ай

– Яздым, сыздым, яздым, сыздым...
Ниһаять, булды әзер:
«Салават күпере»нә
Шигырь җибәрәм хәзер!

Казан.


Диана, 6 яшь



– Уклау алдым кулыма –
Һич вакытым юк минем;
Тиз генә камыр җәеп,
Бәлеш пеширим, димен!

Кайбыч, Хуҗа Хәсән.



– Миңа инде җиде ай –
Үсәргә бик тырышам...
Күрәсезме, әнигә
Кер юарга булышам!

Арча, Иске Чүриле.


Әлфис, 7 ай


Алия, 1 яшь

– Гел эш белән шөгыльләнәм –
Иртә белән, кич белән...
Курчак белән уйнарга да
Вакытым юк һич кенә!

Казан.




Ранис, 1 яшь 5 ай

– Тәпи атлап йөрергә
Шомарып киләм:
Чәчәкләргә таянып,
Юл ярып киләм!

Буа, Бикмураз.


Ралинә, 5 яшь

– Көн саен чәчәк ата –
Бик гаҗәп үсемлек ул:
Сездә – юктыр, бездә – бар, –
Ралинә исемле гөл!

Питрәч, Ленино-Кокушкино.




Нәфисә, 3 яшь
Мәдинә, 1 яшь

– Телим икән – атлый алам,
Мине берни куркытмый...
Тик менә... ни... үләннәр бит...
Аякларны кытыклый!

Актаныш.


Айзилә, 5 яшь

– Әни әйтә: «Кызларның, – ди, –
Урыны күзге каршында».
Миңа, никтер, күбрәк ошый
Йөрү кресло башында.

Балык Бистәсе, Олы Елга.





«Салават күпере» журналының бер санында (2008 ел, март) Ләбиб Леронның «Рәхмәт ишетүе рәхәт» хикәясе басылган иде. Шуңа җавап рәвешендә язабыз.



Мөслим районы,
Октябрь мәктәбенең
4 нче сыйныф укучылары.

Матур яшибез

Без мәктәптә оештырылган төрле чараларда, бәйрәмнәрдә теләп катнашабыз. Һәр бәйрәм үзенчәлекле үтә. Соңгы бәйрәмнәрнең берсе – Гаилә бәйрәме булды. Әти-әниләр белән берлектә узган бу бәйрәм бик күңелле үтте. Көлке көнендә бик рәхәтләнеп көлдек. Кошлар көнендә «Кошлар – безнең канатлы дусларыбыз» дигән стенд эшләдек. Хәзергесе вакытта мәктәп бакчасында мәш киләбез. «Халык иҗаты», «Шахмат», «Спорт» түгәрәкләренә йөрибез.

Безнең матур яшәвебезгә, тырыш булуыбызга әти-әниләребез бик шат. Алардан рәхмәт сүзләрен ишетеп кенә торабыз. Чыннан да, рәхмәт ишетүе рәхәт икән шул.

Ә без, үзебез, әти-әниләребезгә, укытучы Римма апабызга бик рәхмәтле.



Элюза ГАЯНОВА, 6 яшь.
Арча, Үрнәк.



Айназ ХАФИЗОВА.
Әлмәт, Яңа Нәдер.

Көмеш көзге

Әкият

Борын-борын заманда яшәгән, ди, Миләүшә атлы бер кыз. Көннәрдән бер көнне Миләүшә әнисеннән: «Әни-әни, әнием, урманга җиләк җыярга җибәр әле», – дигән. Әнисе аны җибәргән. Менә Миләүшә тиз генә кәрзинен алган да урманга таба киткән. Җиләк җыя-җыя, үзенең адашканын сизми дә калган. Кая барырга белмичә, әле уңга, әле сулга чаба икән. Кинәт ул урман эчендәрәк бер йортка тап булган. Анда бер авыру бабай яши икән. Бабай әйткән: «Бераз кунак бул, аннары кайтырсың», – дигән. Миләүшә бабайга мәтрүшкәле чәй кайнатып эчергән, үзенең җиләкләрен ашаткан. Бабай терелгән. Миләүшә кайтырга җыена башлаган. Бабай аңар бүләк итеп көмеш көзге биргән. Миләүшә көзгене алып, зур рәхмәт әйтеп, бабай күрсәткән юл белән киткән. Бара торгач, ул убырлы карчыкка юлыккан. Карчык аны сихерләп өенә алып кайтмакчы булган. Миләүшә аңа үзенең көзгесен күрсәткән. Убырлы көмеш көзгедән үзен күрүгә, көзге каралып киткән. Убырлы карчык шундык чебен гөмбәсенә әверелгән. Миләүшә исә үз юлы белән киткән. Бара-бара ул өенә ничек кайтып җиткәнен сизми калган. Миләүшә үзенең көмеш көзгесеннән бер дә аерылмый икән. Күңелләре чиста, пакь кешеләр янында көзге ялтырап китә, ә начар кешеләр янында карала икән. Моны белгән кешеләр яхшы булырга тырышканнар. Көмеш көзгенең һәрвакыт ялтырап торуын теләгәннәр.

Динә МОРАДИМОВА, 8 яшь.
Яңа Чишмә, Чаллы Башы.



Лилия НӘБИУЛЛИНА, 10 яшь.
Аксубай, Яңа Дума.

Язны сагыну

Язгы көннәр бик күңелле –
Бар табигать уяна.
Кояш нурын сибә безгә,
Һәрбер кеше куана.

Кошлар кайта җылы яктан
Гөрләп ташулар ага.
Түбәләрдән тамчы тама –
Бар табигать җанлана.

Кайтсыннар, әйдә, кошкайлар
Туган-үскән җирләргә.
Язсын безгә шушы җирдә
Бергә-бергә яшәргә.

Гөлфинә ВӘЛИЕВА, 10 яшь.
Әлки, Иске Салман.



Мин — татлы җимеш



Безнең гаиләдә өч кеше. Әти, әни һәм мин. Гаиләдә иң җаваплы, тырыш кеше – әтием. Аның исеме Радик. Радик ул Радий исеменнән ясалган. Латинча «нур» дигән мәгънә белдерә. Өебездә иң сабыр, матур кеше – әнием. Аның исеме Зөлфия. Зөлфия исеме «бөдрә чәчле, сөйкемле, чибәр» дигәнне аңлата. Ә аларның татлы җимешләре, акыллы, сөйкемле кызлары – мин. Минем исемем Зилә. Зилә исеме – миһербанлы, шәфкатьле, таза-сау, пакь, керсез дигәнне аңлата.

Зилә ИСМӘГЫЙЛЕВА, 8 яшь.
Апас районы, Каратун.

Әби, бабай, Кеша һәм мин

Мин Фәридә исемле булам. Вәрәшбаш төп гомуми белем бирү мәктәбенең 5 сыйныфында укыйм. «Салават күпере» журналын укырга яратам.

Минем әти-әнием юк. Әбием һәм бабай белән яшим. Фоторәсемгә яраткан песием Кеша белән бергә төштем.

Фәридә ХӘМӘТДИНОВА, 10 яшь.
Мөслим, Вәрәшбаш.





Илзидә ЗӘКИЕВА, 6 яшь.
Казан.

Сөенеп яшик

Без гаиләдә бишәү булабыз: әти, әни, сеңлем, энем һәм мин.

Минем әнием Фәния, әтием Рәшит, сеңлем Рузилә, энем Рәзил исемле.

Быел – Гаилә елы. 2007 ел Хәйрия елы иде. Шуңа да мин гаилә турында язарга булдым әле.

Һәрбер кешенең дә үз гаиләсе булырга тиеш. Һәм ул гаиләсендә шатланып, сөенеп яшәргә хокуклы. Менә балалар йортлары бар. Андагы балалар да үз гаиләсен табып, безнең кебек шатланып, сөенеп яшәсеннәр иде. Мин үземнең гаиләмне, туганнарымны бик яратам.

Динә ГАЗАЕВА, 11 яшь.
Апас, Болын-Балыкчы.

Бу биттәге рәсемнәрне Балтач районы Чутай мәктәбе укучылары ясаган.



Булат ВАФИН, 9 яшь.

Кояш нигә елмая?

– Кояш нигә елмая?
– Җирдә әти булганга.
– Кояш нигә елмая?
– Җирдә әни булганга.
– Кояш нигә елмая?
– Без – бәхетле булганга.
Елмай син, кояш, көн дә,
Өләшеп шатлык һәркемгә.

Руфинә КӘРИМОВА, 7 яшь.
Саба, Олы Кибәче.



Райнур ӘҺЛИУЛЛИН, 9 яшь.



Фирая РАМАЗАНОВА, 9 яшь.



Барысын да яратам

Без гаиләдә җиде кеше –
Матур, тигез яшибез:
Әти, әни, әби, бабай,
Игезәкләр белән – өчебез.

Әбинең дә кызы мин,
Бабайның да кызы мин.
Әти белән әнинең,
Тәүге кызы әле мин.

Минем әти уңган шофёр,
Эшләмәгән эше юк.
Аның машинасыннан
Файдаланмаган кеше юк.

Минем әни – укытучы,
Безгә белем бирүче.
Әле тагын игезәкләр бар –
Ясле-бакчада йөрүче.

Әнием минем бик уңган,
Ә әтием тагын да;
Шуңа күрә яратамын
Мин аларның барын да.

Гөлинә КӘРИМОВА, 12 яшь.
Саба, Олы Кибәче.



Даша КУЗНЕЦОВА, 7 яшь.

2008 ел – Гаилә елы. Шул уңайдан бакчада балалар белән берлектә күп кенә чаралар үткәрәбез: рәсемнәр ясыйбыз, шигырьләр язабыз. Кайбер рәсемнәрне сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәбез һәм без яратып укый торган «Салават күпере» журналы битләрендә күрербез дип ышанып калабыз.

Хөрмәт белән,
Бөгелмәдәге 14 нче
балалар бакчасы тәрбиячеләре
Фиалка Фәнис кызы ГАРИФУЛЛИНА,
Ирина Николай кызы ЕФИМОВА.



Арина ЕГОРОВА, 7 яшь.



Лиза ШАРДАКОВА, 6 яшь.



Анджела МИҢНЕГӘРӘЕВА, 7 яшь.



Даша ЕФИМОВА, 6 яшь



Ярослава ПАВЛОВА, 7 яшь.

Безнең әни

Безнең әни бик уңган
Бар эшкә дә өлгерә.
Без бакчадан кайтуга
Тәмле ашлар пешерә.

Без әнине яратабыз,
Ул да безне ярата.
Мәрхәмәтле булырбыз
Без әнигә карата.


Рузинә КӘРИМОВА, 7 яшь.
Саба, Олы Кибәче.

Җәй генә җитсен

Безнең Богады авылы бик матур урынга урнашкан. Аның бер ягыннан Биҗады елгасы агып ята. Җәен каз-үрдәк елгада канат ныгыта. Бала-чага эсселектән качып су коена, ә кышларын су өсләре боз белән каплангач, тимераякта шуа. Авылның икенче ягында басулар җәелеп ята. Авылымнан ерак түгел урнашкан урман табигатенең матурлыгы әйтеп тә, язып та бетергесез. Урман туган җиремнең һавасын сафландырып тора. Җәй җиткәч, мин шул урманда җиләк җыярмын, кошлар сайравын тыңлармын.

Рүзәл НУРИЕВ, 9 яшь.
Актаныш, Богады.

Ребуслы кроссворд



Сулдан уңға:

3. а = о, к = т
5. Я Р К
7. Е ,,,,
8. ' ви
9. К = П ' ла
11. 3 + 7 - 4
12. ' ,,
13. ''''
14. 2.4.2.3
16. ө = а, ә = а
19. , ' М = П
21. ш = р '' ,
22. 2.4.1.5.4
23. ,,, 1000000 м

Астан өскә:

1. 2.5.4 н
2. у ''' ,
3. '' ,
4. 1.5.3.2
5. я ' ,, л
6. рб = в ' н
9. 2.3.5.4 л
10. 2.6.1.5 к
13. т а
15. ды ,,, 90
17. , р ч
18. ' ку = вы
20. м = к
21. 2.6.1.2

Төзеде Гүзәл СӘЕТОВА.

Ребус чишүнең берничә кагыйдәсе.

Сүзнең сул ягындагы өтер – сүз алдыннан, ә сүзнең уң ягындагы өтер (гадәттә, ул борылган кыяфәттә) сүз ахырыннан ничә хәрефне алып ташларга икәнен күрсәтә.



Өй

Борылган рәсем күрсәтелсә, сүз уңнан-сулга укыла. Соңыннан гына сүз янындагы биремнәр үтәлә.



Сан

Кирәк булмаган хәрефләр сызылган рәвештә бирелә. Әгәр ул хәрефләр сүздә берничә икән, аларның барысы да сызыла. Ә инде берәр сан сызылган булса, шул санлы хәреф сызыла.



Кул

Сүз эчендәге хәрефне икенче хәрефкә алыштыру өчен тигезлек билгесе яки ук куела. Әгәр тигезлек 2=А рәвешендә бирелсә, димәк, сүздәге икенче хәреф А хәрефенә алыштырыла.



Ат

Кайвакыт сүзнең берничә хәрефе генә алына. Ул очракта сүз янында 4.1.3 рәвешендә кирәкле хәрефләрнең саннары бирелә.



Тарак

Хәрефләр икенче бер хәрефнең өстендә яки эчендә булырга мөмкин. Бу очракта аларга -да/-дә, -та/-тә кушымчалары да кушылып укыла.



Пәрдә

Журналга язылу бәясе – ярты елга 102 сум

Салават күпере

Индексы– 73953

“САЛАВАТ КҮПЕРЕ”–

мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм кече яшьтәге укучылар өчен чыгарыла торган матур, акыллы, юмарт журнал.

Салават күпере

6(219) — 2008

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал основан в 1990 году.
На татарском языке.

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Алла АЙСИНА рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

Басарга кул куелды 5.06.2008 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ Т-659.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хәснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, З.Вакказова, Г.Сабирова.

татмедиа
ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АЧЫК АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ.

Гомуми тираж 464920 данә
Тираж 11280 данә.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӘСНИЯР

Безнең адрес:
420012 г.Казань, ул.Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

«Идел-Пресс» ААҖ.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Сабантуйда

Бабайларым мәйдан тоткан,
Әтием дә бил алышкан...
Мин дә менә Сабантуйга
Әзерләндем быел кыштан.

Көрәшергә уйлыйм мин дә –
Бабай кебек! Әти сыман!..
Ерак бабаларым миңа
«Бирешмә!» дип әйтер сыман...

Бабайларым мәйдан тоткан...
Бүген мин дә бил алышам:
Мин – батырлар нәселеннән,
Мин алардан һич калышмам!

Бәхтияр ГЫЙЛЬФАНОВ, 14 яшь.
Казан.